Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 ноябрь 2019 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 2 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка авылында 2019 елның 24 ноябрендә узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авылы җирлегенең Сосновка бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Сосновка бистәседә урам утлары челтәрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Никольский авылы, Үзәк урамы, 100 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Дәүләтгәрәев